*Үзәкләштерелгән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте*

# Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ

*Казан - 2014*

*Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте*

# Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ

«Хузур» нәшрият йорты
1436/2014

www.darul-kutub.com

Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Экспертлар шурасының 14-41 нче номерлы карары белән басарга хупланган

Имам-хатыйблар тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында әлеге нигезләмә Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе Р.К. ӘДҺӘМОВ белән килешенгән һәм Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти К.И. СӘМИГУЛЛИН тарафыннан расланган

www.darul-kutub.com

**Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ.** – Казан: Хузур, 1436/2014. – 48 б.

© Үзәкләштерелгән дини оешма –
Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте,
2014

«КИЛЕШЕНГӘН»

Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе

____________________Р.Әдһәмов

2014 нче елның «_____» ___________

«РАСЛЫЙМ»

Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти

_______________ К.Сәмигуллин

2014 нче елның «____» ____________

## Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында

## НИГЕЗЛӘМӘ

www.darul-kutub.com

# НАМАЗЛАР

**Җәмәгать намазлары**

Җәмәгать намазларын укыту мәчет имамының (имамнарының) турыдан-туры вазыйфасы булып тора. Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә җәмәгать намазларын сайлап куелган имамнан (сайлап куелган имамнардан) башка беркем дә уздыра алмый. Шуның белән бәйле рәвештә, имам (имамнар) намазны шәхсән үзләре уздырырга тиеш яисә алар бу эшне кандидатурасы имам-мөхтәсиб белән килештерелгән мәзингә тапшыра.

Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә барлык намазлар да хәнәфи мәзһәбендә билгеләнгән тәртиптә укыла.

Имамга оеп укыла торган фарыз намазларга соңга калып килгәннәргә икенче тапкыр җәмәгать намазы укыту тәкъдим ителми. Әгәр дә мәчет юл кырыенда яисә транспорт юлы янында урнашкан булса — икенче җәмәгать белән намаз уку тыелмый.

**Җәмәгать намазы укыганнан соң башкарыла торган гамәлләр**

اَللَّهُمَّ اَنْتَ السَّلَامُ وَمِنْكَ السَّلَامُ تَبَارَكْتَ يَا ذَا الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ

**«Әллааһүммә әнтәс-сәләәмү үә минкәс-сәләәмү тәбәәрактә йәә зәл-җәләәли үәл-икраам».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, Син — һәрбер бәладән саклаучы. Һәрбер сәламәтлек — Синнән генә. Син — мөбарәк зат, әй олуглык һәм хөрмәт иясе Аллаһы».*

Фарыз (иртәнге һәм икенде намазлары очрагында) һәм сөннәт (өйлә һәм ахшам очрагында) намазлары, шулай ук, ястү булганда — витер намазы беткәннән соң, имам, урыныннан

тормыйча гына, намаз арты зикерләрен әйтер өчен, үзе артында булган кешеләргә йөзе белән борылып утыра.

Намаз арты зикере әйтү тәртибе түбәндәгечә.

Имам кычкырып әлеге доганы укый:

سُبْحَانَ اللهِ وَ الْحَمْدُ للهِ وَ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَ اللهُ أَكْبَرُ وَ لَا حَوْلَ وَ لَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيمِ مَا شَآءَ اللهُ كَانَ وَ مَا لَمْ يَشَأْ لَمْ يَكُنْ

**«Субъхәнәл-лааһи үәл-хәмдү лилләәһи үә ләә иләәһә иллә-лааһү үәл-лааһү әкбәр үә ләә хәүле үә ләә куввәтә иллә билләһил галиил газыйм мәә шәәАлләһү кәәнә үә мәә ләм яшәә ләм якүүн».**

*Мәгънәсе: «Аллаһы тәгалә барлык кимчелекләрдән пакь. Барча мактаулар Аллаһы тәгаләгә хас. Бер Аллаһы тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Аллаһы һәрнәрсәдән олуграк».*

Шуннан соң имам эчтән генә «Аятел-Көрси»не укый, кычкырып бары тик «Аятел Көрси»нең башын гына укый.

Аннары утыз өчәр тапкыр «СүбехәәнәЛлааһи», «ӘлхәмдүлилЛәәһи», «Әллаaһү әкбәр» зикерләрен әйтә, башта — кычкырып, ә аннары эченнән генә кабатлый. Зикерләр әйтелеп беткәч, имам, намаз укучылар белән бергәләп, уч табаннарын өскә каратып, кулларын күкрәк турысына күтәрә һәм дога кыла:

اَللَّهُمَّ تَقَبَّلْ مِنَّا صَلَاتَنَا وَ صِيَامَنَا وَ قِيَامَنَا وَ رُكُوعَنَا وَ قُعُودَنَا وَ سُجُودَنَا وَ تَهْلِيلَنَا وَ تَسْبِيحَنَا وَ تَحْمِيدَنَا وَ تَكْبِيرَنَا وَ تَخَشُّعَنَا وَ تَضَرُّعَنَا. اَللَّهُمَّ تَمِّمْ تَقْصِيرَنَا وَ تَقَبَّلْ تَمَامَنَا وَ اسْتَجِبْ دُعَاءَنَا وَ اغْفِرْ أَحْيَائَنَا وَ ارْحَمْ أَمْوَاتَنَا يَا مَوْلَانَا. اَللَّهُمَّ

احْفَظْنَا يَا حَفِيظُ مِنْ جَمِيعِ الْبَلَايَا وَ الْأَمْرَاضِ. اَللَّهُمَّ يَا مُقَلِّبَ الْقُلُوبِ ثَبِّتْ قُلُوبَنَا عَلَى دِينِكَ وَ طَاعَتِكَ. اَللَّهُمَّ تَقَبَّلْ مِنَّا هَذِهِ الصَّلَاةَ مَعَ جَمِيعِ نُقْصَانَاتِهَا وَ لَا تَضْرِبْ بِهَا وُجُوهَنَا يَا إِلَهَ الْعَالَمِينَ وَ يَا خَيْرَ النَّاصِرِينَ تَوَفَّنَا مُسْلِمِينَ وَ أَلْحِقْنَا بِالصَّالِحِينَ. وَ صَلِّ اللَّهُمَّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى آلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ

**«Әллаһүммә тәкаббәл миннә салəәтәнәә үә сийәәмәнәә үә кыйәәмәнәә үә кыйра’әәтәнәә үә рукүүгәнәә үә сүҗүүдәнә үә кугүүдәнәә үә тәсбиихәнәә үә тәхлиилләнәә үә тәхашшүгәнәә үә тәдаррүгънәә. Әллааһүммә тәммим тәкъсыйранәә үә тәкаббәл тәмәәмәнәә үәс-тәҗиб дугаә’ әнәә үәгъфир әхйәә’әнәә үәрхәм мәүтәәнәә йәә мәүләәнәә. Әллааһүммәх-фәзнәә йә фәййәду мин җәмиигил-бәләәйә үәл-әмрадъ. Әллааһүммә тәкаббәл миннәә һәәзиһис-саләәтә (әл-фәрда мәгәс-сүннәти) мәгә җәмиги нүксаанәәтиһәә бифәдликә үә кәрамикә үә ләә тәдриб биһәәтвүҗүүһәнәә йәә иләәһәл-гәәләмиинә үә йәә хайран-нәсыриин. Тәүәффәнәә мүслимиин үә әлхикнәә бис-саалихиин. Үә сал-лаллааһү тәгәәлә галәә хайри халкиһии Мүхәммәдин үә галәә әәлиһии үә әсхәәбиһии әҗмәгиин».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, безнең намазларыбызны, уразаларыбызны, кыямыбызны, рөкугыбызны, сәҗдәбезне, кагъдәбезне, тәсбихебезне, тәһлилебезне, тыйныклыгыбызны һәм ялваруларыбызны кабул кыл. Йә Рабби, кимчелекләр белән кылынган гамәлләребезне камилләштер, тәмам булган гамәлләребезне, догабызны кабул кыл. Әй Хуҗабыз, тере булучыларны ярлыка һәм үлгәннәргә рәхмәтеңне ирештер. Әй рәхмәт кылучы Аллаһы, Үз камиллегең һәм юмартлыгың белән бездән ошбу*

www.darul-kutub.com

*намазыбызны һәрбер кимчелекләре белән кабул кыл. Ул намазларыбызны йөзләребезгә ыргытма. Әй бөтен галәмнәрнең Раббысы һәм ярдәм итүчеләрнең иң камилрәге, безне мөселман хәлебездә вафат кыл һәм изге кешеләр белән бергә ит. Мәхлукларның иң яхшырагы Мөхәммәд галәйһиссәламгә, аның әһеленә (гаиләсенә), барлык сахабәләренә рәхмәтеңне бирсәң иде».*

Имам дога кылып бетергәннән соң, куллары белән битләрен сыпыра. Аннан соң Коръән укып дога кылырга киңәш ителә. Иртәнге һәм ахшам намазларыннан соң өч мәртәбә «Ихлас» белән «Фәләк», «Нәс» сүрәләрен уку да хәерле.

Намаздан соңгы зикерләрне бары тик биш вакыт намазларның фарызлары һәм сөннәтләре, шулай ук җомга намазының сөннәте укылганнан соң гына әйтү тиеш. Намаздан соңгы зикер әйтүне әзерлеге булган мәзин дә уздыра ала.

Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә таралган гореф-гадәт буенча, намаздан соңгы зикер әйтелгәннән соң мәхәллә кешеләре, кулларын бирешеп, бер-берсен сәламли, шуннан соң кыска гына дога укыла.

## ҖОМГА НАМАЗЫ

**Вәгазьнең структурасы**

Җомга вәгазе ике өлештән — хөтбә һәм вәгазьдән тора.

Вәгазь шулай ук ике өлешкә — нәсыйхәт һәм рәсми өлешкә бүленә.

**Хөтбә**

Аллаһыга мактаулар (*зикерләр*) булган хөтбә тирән эчтәлекле җомга намазы шарты булып тора.

Хөтбә шулай ук ике өлештән тора. Беренче өлештә Аллаһы тәгаләгә зикер әйтелә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсе әһелләренә, гадел хәлифләргә һәм көрәштәшләренә изге теләкләр, тәшәһһөд, диндәшләргә үгет-нәсыйхәт әйтелә, Коръән-Кәримнән өзекләр китерелә. Икенче өлештә, тәкъвалыкның башка рәвешләреннән тыш, имам дингә ышанучылар өчен дога кыла. Хөтбәнең ике өлеше бер-берсеннән имамның бераз утырып торуы белән бүленә.



www.darul-kutub.com

Хөтбә җомга намазы кергән вакыттан (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә кабул ителгән намаз вакытлары нигезендә) намаз башланганчыга кадәр укыла.

Тәкъдим ителүче хөтбә тексты үрнәкләре Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие тарафыннан раслана.

Хөтбә гарәп телендә укыла.

Хөтбә вакыты өч минуттан да артык булырга тиеш түгел.

**Вәгазь**

Вәгазь җомга намазы кергәнче (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә кабул ителгән намаз вакытлары нигезендә) укыла.

Вәгазь хөтбәгә өстәмә булырга, ягъни җомга намазы җиткәч тә укылырга мөмкин.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлешендә имам-хатыйб тыңлаучыларга мөселман диненең төп нигезләмәләрен һәм рухый-әхлакый үгетләрне җиткерә. Монда ул Коръәнгә һәм Сөннәткә таяна, пәйгамбәрләр, Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вә сәлләм), аларның көрәштәшләре, исламның игелекле ир-атлары тормышыннан мисаллар китерә һәм мәхәлләнең игътибарын дин тотучының рухый тормышын тәшкил итүче барча нәрсәгә юнәлтә.

Вәгазьнең рәсми өлешендә имам мөселманнарга Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми хәбәрләрен (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте корылтае, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте пленумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте президиумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте баш казые, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы карарларын), шулай ук оештыру мәсьәләләренә кагылышлы төбәк (шул исәптән, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең төбәк казыят-

www.darul-kutub.com

ләре карарлары) һәм җирле (шул исәптән, мәхәллә җыелышы һәм мәхәллә советы карарлары) әһәмияттәге башка кирәкле мәгълүматны җиткерә.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәхәлләренә йөрүчеләргә җиткереләчәк рәсми мәгълүматның эчтәлеген Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие билгели. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәсми мәгълүматын мөселманнарга җиткерүне районның имам-мөхтәсибе тикшереп тора.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлеше Коръән-Кәримгә һәм Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияргән, имам Әбү Хәнифә дини-хокукый юнәлеше нигезендә фәкыйһ һәм галәмалар иҗтиһадында чагылыш тапкан Коръән, Сөннәт һәм шәригать нормаларындагы хакыйкать нигезендә бәян ителә.

Исламның дини абруйлары сыйфатында таянырга ярамаган затлар, шулай ук үрнәкләре һәм мираслары вәгазьләрдә искә алынырга тәкъдим ителгән затлар исемлеге Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Голәмалар шурасы тарафыннан билгеләнә һәм мөфти хәзрәтләре тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары вәгазе татар телендә алып барыла. Бик сирәк очракларда, максатка ярашлылык принцибыннан чыгып, җомга намазы вәгазьләрен рус һәм башка телләрдә өстәмәләр белән уку рөхсәт ителә. Вәгазьләрне рус һәм башка телләрдә өстәмәләр белән уку өчен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтиенең махсус рөхсәте кирәк.

Вәгазьнең дәвамлылыгы, әгәр ул намаз вакытына кадәр укылса — кырык минуттан артмаска, ә намаз вакыты кергәннән соң укылса — егерме минуттан озаграк булмаска тиеш.

**Җомга намазын үткәрү тәртибе**

*I вариант*

Җомга намазы җиткәнче, имам дин тотучыларга вәгазь белән мәрәҗәгать итә.

Мәзин җомга намазына чакыра торган беренче азанны әйтә.

Имам һәм мәхәллә дүрт рәкәгать сөннәтне укый.



www.darul-kutub.com

Мәзин тагын җомга намазына чакыра торган икенче азанны әйтә.

Имам мөнбәргә күтәрелә.

Имам хөтбәнең беренче өлешен сөйли.

Имам мөнбәр баскычына утыра (ике вәгазь арасында утырып тору).

Имам хөтбәнең икенче өлешен укый.

Имам җомга намазының фарыз өлешен башкару өчен мөнбәрдән төшә.

Мәзин җомга намазының фарыз өлешен башкаруга чакыручы камәт әйтә.

Имам җитәкчелегендә мәхәллә мөселманнары җомга намазының фарыз өлешен укый.

*II вариант*

Мәзин җомга намазына чакыра торган беренче азанны әйтә.

Имам һәм мәхәллә халкы дүрт рәкәгать сөннәтне укый.

Имам дин әһелләрен сәламли һәм мөнбәргә менә.

Мәзин тагын бер кат җомга намазына чакыра торган икенче азанны әйтә.

Имам хөтбәнең беренче өлешен укый һәм дин тотучыларга вәгазь сөйли.

Имам мөнбәр баскычына утыра (ике вәгазь арасында утырып тору).

Имам хөтбәнең икенче өлешен укый.

Имам җомга намазының фарыз өлешен башкару өчен мөнбәрдән төшә.

Мәзин җомга намазының фарыз өлешен башкаруга чакыручы камәт әйтә.

Имам җитәкчелегендә мәхәллә мөселманнары җомга намазының фарыз өлешен укый.

Җомга намазын кайсы вариант буенча үтәү имам-хатыйб һәм мәхәллә белән килештерелә.

www.darul-kutub.com

# БӘЙРӘМ НАМАЗЫ

**Вәгазь**

Вәгазь ике өлештән — нәсыйхәт һәм рәсми өлешләрдән тора.

Вәгазь бәйрәм намазы укылганчы сөйләнә.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлешендә имам-хатыйб тыңлаучыларны мөселман диненең бәйрәм намазы укыла торган бәйрәм белән бәйле төп нигезләмәләре белән таныштыра.

Вәгазьнең рәсми өлешендә имам мөселманнарга Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми хәбәрләрен (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте корылтае, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте пленумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте президиумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте баш казые, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы карарларын), шулай ук оештыру мәсьәләләренә кагылышлы төбәк (шул исәптән, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең төбәк казыятләре, район мөхтәсибәте карарлары) һәм җирле (шул исәптән, мәхәллә җыелышы һәм мәхәллә советы карарлары) әһәмияттәге башка кирәкле мәгълүматны җиткерә. Рәсми мәгълүмат вәгазь ахырында җиткерелә.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәхәлләренә җиткерелергә тиешле рәсми мәгълүматның эчтәлеген Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие билгели. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәсми мәгълүматын мөселманнарга җиткерүне районның имам-мөхтәсибе тикшереп тора.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлеше Коръән-Кәримгә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияргән, имам Әбү Хәнифә дини-хокукый юнәлеше һәм Әбү Мансур әл-Матуриди тәгълиматлары нигезендә фәкыйһ һәм Голәмалар иҗтиһадында чагылыш тапкан Коръән, Сөннәт һәм шәригать нормаларындагы хакыйкать нигезендә бәян ителә.

Исламның дини абруйлары сыйфатында таянырга ярамаган затлар исемлеге Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Голәмалар шурасы тарафыннан билгеләнә һәм мөфти хәзрәтләре тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары вәгазе татар телендә алып барыла. Бик сирәк очракларда, максатка ярашлылык принцибыннан чыгып, бәйрәм вәгазьләрен рус телендә өстәмәләр белән уку рөхсәт ителә. Вәгазьләрне рус телендә өстәмәләр белән уку өчен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтиенең махсус рөхсәте кирәк.

Бәйрәм вәгазенең дәвамлылыгы егерме минуттан да ким булмаска һәм утыз минуттан да артмаска тиеш.

**Хөтбә**

Аллаһыга мактаулар (*зикерләр*) булган хөтбә тирән эчтәлекле бәйрәм намазының шарты булып тора.

Хөтбә шулай ук ике өлештән тора. Беренче өлештә Аллаһы тәгаләгә зикер әйтелә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсе әһелләренә, гадел хәлифләргә һәм көрәштәшләренә изге теләкләр, тәшәһһөд, диндәшләргә үгет-нәсыйхәт әйтелә, Коръән-Кәримнән өзекләр китерелә. Икенче өлештә, тәкъвалыкның башка рәвешләреннән тыш, имам дингә ышанучылар өчен дога кыла. Хөтбәнең ике өлеше бер-берсеннән имамның бераз утырып торуы белән бүленә.

Хөтбә — бәйрәм намазы укылганнан соң сөйләнә. Хөтбә тәмамлангач, имам мөселман халкын бәйрәм белән котлый, аннары кардәшләр бер-берсенә кул бирешә һәм бер-берсен тәбрикли.

Тәкъдим ителә торган кануни хөтбә тексты үрнәкләре Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие тарафыннан раслана.

Кануни хөтбә гарәп телендә укыла.

www.darul-kutub.com

**Бәйрәм намазын үткәрү тәртибе**

Имам мөнбәргә менә һәм вәгазь сөйли.

Бәйрәм намазы вакыты кергәннән соң, имам намаз вакыты җитүен әйтә һәм мөнбәрдән төшеп, намаз укучыларга рәтләргә тезелергә куша. Имамга шуны истә тотарга кирәк, бәйрәм намазында өстәмә тәкбирләр әйтү мәҗбүри (ваҗиб) гамәл булып тора. Беренче рәкәгатьтә — истигаза укыр алдыннан — өч тәкбир һәм икенче рәкәгатьтә рөкугъ алдыннан өч тәкбир әйтелергә тиеш. Шулай ук әлеге тәкбирләрнең кирәклеге турында намаз укучыларның исләренә төшерү дә лазем. Ахырдан намаз укыла.

Намаз вакытында имам Коръән аятьләрен кычкырып укырга, «Фатихә» сүрәсеннән соң *«амин»* сүзен эчтән генә әйтергә тиеш.

Ураза бәйрәме өчен түбәндәге кануни вәгазь тәкъдим ителә.

Беренче өлеше:

بِسْــــــــــمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ
اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَ اللهُ أَكْبَرُ اَللهُ
أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ
الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَ الْإِيمَانِ وَ شَرَحَ صُدُورَ
الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَ الْعِرْفَانِ وَ أَكْرَمَ عِبَادَهُ
الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ
أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَاللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ
الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ
الرَّحْمَةِ وَ الْغُفْرَانِ وَ غَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ

www.darul-kutub.com

النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ
بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ
الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ
إِلاَّ الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ،

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ
وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۞ اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ
لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَاللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ ۞
وَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ
ذُوالْعَفْوِ وَ الْغُفْرَانِ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ
رَسُولُهُ صَلَى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَ عَلَى آلِهِ وَ
أَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ ۞ أَيُّهَا
النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَ نَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى
اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ
الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَالَّذِينَ
هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ فِي الْقُرْآنِ
الْعَظِيمِ وَ نَفَعَنَا وَ إِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَ الذِّكْرِ الْحَكِيمِ
إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ
السَّمِيعُ الدُّعَاءَ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим.

Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәүүәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти үәл-иимәән, үә шәрахә судүүрас-садикыйинә би шәрхил-һидәәйәти үәл-гыйрфәән, үә әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-сааимиинә әбүәәбәр-рахмәти үәл-гуфраан, үә галләка галәс-сааимиинә әбүәәбән-нийрани фи шәһри рамәдаан. Үәгадә лис-сааимиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүү-һүү илләс-сааимүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләзии үнзилә фииһил-куръәәнү һүдәл-линнәәси үә бәййинәәтим-минәл-һүдәә үәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһүү зүл-гафьүи үәл- гуфраан, үә әшһәдү әннә Мүһәммәдән габдүһүү үә расүүлүһүү. Салләллааһү тәгаалә галәйһи үә галәә әәлиһи үә әсхәәбиһии саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән.

Әййүһәннәәс, үүсыйикүм гыйбәәдәллааһи үә нәфсии әүүәлән-битәкъүәллааһ. Әгуузу билләәһи минә шәйтаа-нир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгаллләзиинәт-тәкау үәлләзиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә үә ләкүм фил-куръәәнил-газыйим, үә нәфәганәә үә иййәәкүм бил-әәйәәти үәззикрил-хәкиим, иннәһүү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-газыйиму сәмиигуд-дүгааъә.

*Мәгънәсе: «Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән.*

*Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыга гына мактау. Аллаһыга якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) вә иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидәят һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына рамазан ае уразасын бүләк иткән зат барча*



www.darul-kutub.com

*кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм (ахырзаман пәйгамбәре) хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр — аңа Раян диелә. Ул ишектән рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Коръәндә әйтә: «Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу итүче һәм мәгъфирәт иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм — Аның колы һәм рәсүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сахабәләренә Аллаһы тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһының коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Коръәндә әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) гафу итүче, рәхимле, юмартлык иясе, олуглык иясе, бөек зат һәм догаларны ишетүче, кабул итүче».*

Икенче өлеше:

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ
نُؤْمِنُ بِهِ وَ نَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَ نَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ

www.darul-kutub.com

أَنْفُسِنَا وَ مِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَ مَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ ۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ وَ سَلِّمْ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَ الْمُرْسَلِينَ وَ عَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَ عَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَ عَلَى أَهْلِ الطَّاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَ الْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَ الْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ وَ ارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَ احْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

Иннәл-хәмдә лилләәhи нәхмәдүhүү үә нәстәгыйинүhүү үә нәстәгъфируhүү үә нуъминү биhии үә нәтәүәккәлү галәйhи үә нәгуузү билләәhи миң шүруури әнфүсинәә үә миң сәййиәәти әгъмәәлинәә мәййәhдииhилләәhү фәләә мүдыйллә ләhүү үә мәй-йүдълилhү фәләә hәәдиә ләh. Үә әшhәдү әлләә иләәhә илләллаhү үәхдәhүү ләә шәриикә ләh, үә әшhәдү әннә Мүхәммәдән габдүhүү үә расүүлүh. Аллаhүммә салли үә сәллим галәә җәмигыйль-әнбийәәи үәл-мүрсәлиин, үә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиин. Үә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйин, үә галәә әhли таагатикә әҗмәгыйин, мин әhлиссәмәүәәти үәл-ардыйин. Аллаhүммә гъфир лилмүэминиинә үәл-мүэминәәт, үәл-мүслимиинә, үәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минhүм үәл-әмьүәәт, үәрхәмнәә мәгаhүм. Үәхшүрнәә мәгаhүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

*Мәгънәсе: «Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһыга, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһыга үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы тәгалә һидәят бирсә — аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса — аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә. Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм — Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә — булсыннар алар күк әһелләреннән һәм булсыннар алар җир әһелләреннән — барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит, йә рәхимлеләрнең иң рәхимлесе».*

Корбан бәйрәме өчен түбәндәге кануни вәгазь тәкъдим ителә.

Беренче өлеше:

اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَاللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ
أَكْبَرُ وَ لِلّٰهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ
الشِّرْكِ وَ الزَّوَالِ وَ نَطَقَتِ الأَدِلَّةُ بِأَوْصَافِهِ الْجَلَالِ
وَ الْجَمَالِ. اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لا إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَاللّٰهُ
أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَ لِلّٰهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي
كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَ الْأَفْهَامُ وَ عَجَزَ عَنْ إِدْرَاكِ

www.darul-kutub.com

صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الأَعْلامُ. اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَاللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ.
سُبْحَانَ مَنْ أَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَ الْأَيَّامِ وَ أَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْأَيَّامِ عَلَى الْأَغْنِيَاءِ الْحَجَّ وَ الطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.
اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَاللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللّٰهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَ لَا وَلَدًا وَ لَمْ يَكُنْ لَهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَ لَمْ يَكُنْ لَهُ وَلِيٌّ مِنَ الذُّلِ وَ كَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَ أَشْهَدُ أَنَّ لَا إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِأَمْرِ اللّٰهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ. صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَ أَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِأَحْسَنِ الْأَخْلَاقِ وَ أَطْيَبِ الْأَحْوَالِ.
أَيُّهَا النَاسُ! اِعْلَمُوا أَنَ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَطِيفٌ لِلْخَوَاصِّ وَ الْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدْرُهُ لِلْأَنَامِ عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْإِنْعَامِ وَ الإِحْسَانِ وَ إِيصَالِ الْأَرْحَامِ إِنَ اللّٰهَ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى أَوْجَبَ

عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ (وَانْحَرْ) وَ أَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْأَشْهَرِ وَ أُفْدِيَ بِكَبْشٍ مِنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَ لَا يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَ الضَّأْنُ وَ الْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزَأَةٌ وَ لَا يَجُوزُ الْعَجْفَاءُ وَ الْعَرْجَاءُ وَ مَقْطُوعَةُ الْأُذُنِ وَ الْإِلْيَةِ وَ الَّذِي لا يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ. ضَحُّوا عَنْ أَطْيَبِ أَمْوَالِكُمْ وَ عَظِّمُوهَا إِمْتِثَالاً لِأَمْرِ رَسُولِ اللهِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ:» عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَإِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ« وَ إِنَ اللهَ تَعَالَى أَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ إِلَى آخِرِ أَيَامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: (وَاذْكُرُوا اللهَ فِي أَيَامٍ مَعْدُودَاتٍ) أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَيْطَانِ الرَّجِيمِ:(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللهَ وَ لْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَ اتَّقُوا اللهَ إِنَّ اللهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ) بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ فِي الْقُرْآنِ الْعَظِيمِ وَ نَفَعَنَا وَ إِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَ الذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَ أَسْتَغْفِرُ اللهَ الْغَفَّارَ لِي وَ لَكُمْ

وَ لِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ أَجْمَعِينَ إِنَهُ
هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَّادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

Аллааһү әкбәру, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәл-лааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр үә лилләһил-хәмде. Сүбхәәнә мәң тәкаддәсә зәәтүһүү ганиш-ширки үәззәүәәл. Үә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли үәл-җәмәәл.

Аллааһү әкбәру, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәл-лааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмде. Сүбхәәнә мән тәхәййәра фии күнһи зәәтиһил-гукуулү үәл-әфһәәм, үә гәҗәзә гән идраки сыйфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәру, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәл-лааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмде. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри үәл-әййәәмил-фисааль. Үә әүҗәбә фии һәәзиһил-әййәәми галәл-әгънийәәәил-хәҗҗә үәттауәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгәәль.

Аллааһү әкбәру, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәл-лааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмде. Нәхмәдуллааһәл-ләзии ләм йәттәхыйз саахибәтәү-үә ләә үәләдә, үә ләм йәкүлләһү шәриикүн фил-мүлки, үә ләм йәкүлләһү үәлийййүм-минәз-зүлли үә кәббирһү тәкбиираа. Үә әшһәду әлләә иләәһә илләллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Үә әшһәду әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһүү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәәи би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгәәль. Салләллааһү тәгааләә үә сәлләмә галәйһи үә галәә әәлиһии үә әсхәәбиһил-мәүсуфиинә би әхсәнил-әхъләәкый үә әтъйәбил-әхвәәл.

Әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәзәә йәүмүн шәриифү үә гыйидүл ләтыййифүл лил-хауәәссый үәл-гауәәмм. Йәүмүн газыйимүң кадруһүү лил-әнәәм. Газзыймүү һәәзәл йәүмә бил-ингәәми үәл-ихсәәни үә иисаалил-әрхәәм. Үә иннәл-лааһә тәбәәракә үә тәгаалә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи «Үәнхәрь». Үә әмәра халииләһүү би зәбхи үәләдиһил-әшһәри үә үфдийә би кәбәшим-минәл-җәннәти би үәәсыйтатил-мәләкил-мукарраб, үә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр, үәл-бүднәтү ган сәбгәтин үәд-даъну үәл-мәгзү



www.darul-kutub.com

ган үәәхидин мүҗзиәтү үә ләә йәҗүүзүл-гаҗфәәә-ү үәл-гаръ-җәәәъү үә мәкътуугатүл-үзүни үәл-илйәти үәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гыйндәл-мәзһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү гән әтъйәби әмүәәликүм үә газзыймүүһәә мтисәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи үә сәлләм: «Газзыймүү дахәәйәәкүм фә иннәһәә галәс-сыйраати мәтаайәәкүм». Үә әннәллааһә тәгааләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гакыйбәл-фәръды миң фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһии «Үәзкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүзү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: йәә әййүһәлләзиинә әәмәнүт-тәкуллааһә үәлтәңзур нәфсүм-мәә каддәмәт лигаад. Үәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимә тәгъмәлүн. Бәракә Ллаһу ләнә үә ләкум фил-Куръәнил-газыйм, үә нәфәганәә үә ийәкум бил-әәйәәти үәз-зикрилхәкиими үә әстәгъфирул-лаһәл-гаффәәра лии үә ләкүм үә лисәәири җәмәәгатил-мүслиминәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһүү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-галиим.

*Мәгънәсе: «Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр һәм Аллаһыга мактаулар булсын!*

*Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлуклар дәлил булып тора.*

*Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр һәм Аллаһыга мактаулар булсын!*

*Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле зат булганына) акыл ияләре хайран калды.*

*Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.*

*Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр һәм Аллаһыга мактаулар булсын!*

*Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә*



www.darul-kutub.com

*байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән зат барча кимчелекләрдән пакьтер.*

*Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр һәм Аллаһыга мактаулар булсын!*

*Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында ширкәте булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, аның тиңдәше юк, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аның колы һәм рәсүледер. Ул (Мөхәммәд галәйһиссәлам) җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.*

*Аллаһы тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сахабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.*

*Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы тәбәракә вә тәгалә корбанны: «Корбан чал!» — дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек — җиде кешедән һәм бәрән вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.*

*Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз һәм, Аллаһы рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әмеренә буйсынып, корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының рәсүле галәйһиссәлам әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дигәндә, алар сый-*

*рат күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир-тәшрикъне, Гарәфәт көненең иртәнге намазыннан алып, тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», — дигән. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Коръәндә әйтә: «Әй иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы тәгалә эшләрегездән хәбәрдар» («Хәшер» сүрәсе, 18 нче аять).*

*Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, Аллаһы каршында истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — гафу итүче, рәхимле, данлы, юмартлык иясе, ишетүче һәм белүче».*

Икенче өлеше:

الْحَمْدُ لِلّٰهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نُؤْمِنُ
بِهِ وَ نَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَ نَعُوذُ بِاللّٰهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا
وَ مِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللّٰهُ فَلَا مُضِلَّ لَهُ
وَ مَنْ يُضْلِلْهُ فَلَا هَادِيَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا
اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ
وَ رَسُولُهُ.(إِنَّ اللّٰهَ وَ مَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ.
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَ سَلِّمُوا تَسْلِيمًا)
اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى آلِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ

www.darul-kutub.com

صَلَّى وَ صَامَ. اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى آلِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ و قَامَ. صَلِّ وَ سَلِّمْ عَلَيْهِ وَ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَ الْمُرْسَلِينَ وَ عَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَ عَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَ الْأَرْضِينَ وَ ارْحَمْنَا وَ احْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَ الْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ الْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ إِنَّكَ أَنْتَ مُجِيبُ الدَّعْوَاتِ وَ مُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَ رَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَ قَاضِي الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ. اَللَّهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءِ الرَّاشِدِينَ وَ الْأُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَ كَانُوا يَعْدِلُونَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللهِ (إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَ الْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَ يَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَ الْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ). اُذْكُرُوا اللهَ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرُكُمْ وَ اشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَ

اسْتَغْفِرُوْه يَغْفِرْ لَكُمْ وَ لَذِكْرُ اللهِ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى
أَعْلَى وَ أَوْلَى وَ أَعَزُّ وَ أَجَلُّ وَ أَعْظَمُ وَ أَتَمُّ وَ
أَكْبَرُ.

Әлхәмду лилләәһи нәхмәдуһүү үә нәстәгыйинуһүү үә нәстәгъфируһүү үә нуъмину биһии үә нәтәүәккәлү галәйһи үә нәгүүзү билләәһи мин шуруури әңфүсинәә үә миң, сәййиәәти әгъмәәлинәә мәй-йәһдиһиЛләәһү фәләә мудыйллә ләһүү үә мәй-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Үә әшһәду әлләә иләәһә илләллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ, үә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ. Иннәллаһә үә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбийии. Йәә әййүһәлләзиинә әәмәнү саллүү галәйһи үә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәди үә галәә әәли Мүхәммәд бигадәди мәң салләә үә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәди үә галәә әәли Мүхәммәд бигадәди мән кагәдә үә каам, саллии үә сәллим галәйһи үә галәә җәмиигыйль-әнбийәәи үәл-мүрсәлиин. Үә галәә мәләәикәтикәл-мукаррабиинә үә галәә әһли таагәтикә әҗмәгыйн мин әһлис-сәмәәүәәти үәл-әрадыйин. Үәрхәмнәә үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмүъминиинә үәл-мүъминәәт, үәл-мүслимиинә, үәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм үәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгаүәәт үә мүнзилүл-бәракәәт, үә раафигуд-дәраҗәәт, үә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин. Аллаһүммәр-хәмил хуләфәәә-әр-раашидиин үәл-үмәрааа-әл-мәдыйнәл-ләзиинә кадау билхәккый үә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиин үәһди мән һәзәләддиин. Гыйбәәдәллааһ, иннәллааһә йәәмүрү билгадли үәл-ихсәәни үә ийтәәәи зил-курбәә үә йәнһәә ганилфәхшәәәи үәл-мүнкәр үәл-бәгъйи йәгыйизүкүм ләгалләкүм тәзәккәрүүн. Үзкүруллааһәл-галиййәл-газыймәл-хәййәл-каййүүм, йәзкүрүкүм үәшкүрүүһү йәзидкүм, үәстәгъфируүһүү йәгъфир ләкүм үә ләзикруллааһи тәбәәракә үә тәгааләә әгъләә үә әүләә үә әгаззү үә әҗәллү үә әгъзаму үә әтәмму үә әкбәр.

www.darul-kutub.com

*Мәгънәсе: «Аллаһыга мактау булсын, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыгынабыз. Кемгә Аллаһы һидәят бирсә — аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидият бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм — Аның колы һәм хак илчесе булуына гуаһлык бирәм.*

*«Шик юктыр ки, Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күп салаватлар әйтә. Әй иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».*

*Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәре салават ирештер.*

*Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәре салават ирештер.*

*Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (рәсүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә һәм җирләрдә яшәүче, Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.*

*Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син догаларны кабул итүче, бәрәкәт иңдерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.*

*Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.*

*Аллаһым, кем дингә ярдәм итә — шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә — шуңа һидәят бир.*

www.darul-kutub.com

*Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.*

*Бөек, олуг, тере, уяу булган Аллаһыны зикер итегез — Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез — Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз — Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы тәбәракә вә тәгаләне зикер итү исә — иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәлаләтле, иң бөек, иң камил, иң зур гамәл».*

Шуны да истә тотарга кирәк, зөлхиҗҗә аеның тугызынчы көненең иртәнге намазыннан алып унөченче көннең икенде намазына кадәр — һәр намазның фарызыннан соң — һәр мөселман тәшрикъ-тәкбир әйтергә тиеш. Тәкбир гыйбарәсе болай: *«Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, лә иләһә иллаллаһу Валлаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил хәмде».*

**Җеназа**

Кеше вафат булыр алдыннан, башын Кәгъбәтулла ягына каратып, аны уң ягына яткырырга кирәк. Әгәр нинди дә булса сәбәпләр аркасында болай эшләү мөмкин булмаса, йөзен һәм аякларын кыйблага каратып, башын күтәребрәк куялар. Алай да кыен булса, аңа ничек җайлы — шулай итеп яткырырга кирәк. Мәҗбүр итмичә, йомшак кына түбәндәге сүзләрне әйтергә ярдәм итү тиешле:

لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ مُحَمَّدٌ رَسُولُ اللهِ

**«Ләә иләһә илләл-лаһ, Мухәммәдәр-расүлүллаһ»** *(«Аллаһы тәгаләдән башка һичбер гыйбадәт кылырга лаеклы илаһ юктыр, Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) — Аллаһының илчеседер»).* Әгәр ул әлеге сүзләрне әйтсә — аның белән сөйләшмәү хәерле, аның гомерендә изге сүзләр соңгысы булып калсын. Шулай ук «Йәсин» сүрәсен уку киңәш ителә.

www.darul-kutub.com

Үлгән кешенең күзләрен яптырырга, башын, авызы ачылмасын өчен, иягеннән баш түбәсенә бәйләп куярга, бөкләнгән булсалар — аяк-кулларын турайтырга кирәк. Мәетне, алгы ягы һәм аяклары белән кыйблага таба каратып, биегрәк урынга салалар, кул бармакларын бергә кушалар, кулларын як-якка сузып аякларын янәшә салалар; эче күпермәсен өчен аның өстенә тимер кайчы куярга тәкъдим ителә, тәнен үтә күренмәле булмаган җиңел тукыма белән капларга кирәк.

Үлгән кешене шул ук көндә күмү мөмкин булмаганда, берничә хатын-кыз төне буе мәет саклый, тәһлил әйтә, Коръән укый, вәгазь сөйли һәм кәфенлек әзерли.

Мәетне юганга кадәр аның янында Коръән-Кәрим аятьләре уку рөхсәт ителә. Үлгән кешенең бөтен туганнарына һәм якыннарына үлеме турында хәбәр итәргә, мәетне күмүгә хәзерлек эшен тизләтергә, әгәр дә бурычы калган булса, аның өстеннән җаваплылыкны төшерү өчен, тиз арада аны түләргә, шулай ук үлгән кешенең васыятьнамәсе булса, аны тапшыруны тизләтергә кирәк.

**Мәетне юу**

Юу өчен мәетне хуш исле матдә белән эшкәртелгән махсус тагаракка (колашага) салалар, киемнәрен салдыралар һәм гаурәтен (кендегеннән алып тезләренә кадәр) материя кисәге белән каплыйлар.

Мәетне юганда түбәндәгеләрне үтәү тиешле:

- ♦ мәеткә бары тик кирәк булганда гына карарга;
- ♦ әгәр дә аның гәүдәсендә үзе исән вакытта яшереп килгән җитешсезлекләр ачыкланса — аны беркемгә дә әйтмәскә;
- ♦ мәетне аерым бүлмәдә — кеше күзеннән яшерен почмакта — юарга;
- ♦ мәетнең гаурәтенә карарга, шулай ук аңа кул белән орынырга ярамый, шуңа күрә мәетне юганда дүрт мөселман әһеленә мәет өстендә материя кисәген тотып тору киңәш ителә;
- ♦ мәетнең гаурәт җирләрен юганда чүпрәк яисә шуңа охшаш бер нәрсә куллану ваҗиб (мәҗбүри) саналса, мәетнең башка җирләрен юганда исә — чүпрәк куллану тәкъдим генә ителә;

♦ мәет юа торган бүлмәдә булган барлык көзгеләрне ябарга кирәк, әгәр дә аларны каплау мөмкин булмаса — ул мәҗбүри түгел;

♦ мәетне юа торган су җылы булырга тиеш, суга сабын вә хуш исле әйберләр кушу рөхсәт ителә;

♦ мәет юганда ярдәмчеләр яисә билгеле бер кешеләр генә була.

Аннары мәетнең нәҗесе сөртелә (моның өчен мәетнең эчен җиңелчә генә сыпырырга, нәҗесне чыгару өчен арт юлын юганда суны күбрәк салырга, аннары корытырга кирәк), мәет юучы, үз кулын чүпрәк белән урап, мәетнең гаурәтен сабынлап юа (ягъни истинҗә кылдыра).

Шуннары, авызын һәм борынын чайкамыйча гына, тәһарәт (вүду) алдыралар, чөнки мәетнең борынына яисә авызына су керсә, ул эчкә эләгәчәк, шулай да юеш чүпрәк белән аның авыз-борынын аерым-аерым сөртеп алу тәкъдим ителә.

Аннары түбәндәге рәвештә мәет юуның беренче мәҗбүри гамәлләре башкарыла: сабын вә мунчала белән башын һәм сакалын әйбәтләп юалар, аннары, сабынны суга тидереп, тагын бер кат чиста су белән юалар. Аннан соң мәетнең башын, йомшак кына алга таба идереп, бармак белән авызын, тешләрен, борынын юалар (мәетнең эченә су керүдән сакланырга кирәк); тырнак асты чистартыла; шуннан соң мәетне сул ягына салып, сабын һәм мунчала белән баш очыннан алып аяк очларына кадәр уң ягы юыла, уң ягына салып, шулай ук сабын һәм мунчала белән, сул ягын юалар, әйләндергән саен мәет өстенә өч мәртәбә яисә аннан да күбрәк тапкыр су коялар.

Алга таба мәетне икенче һәм өченче тапкыр тулысынча юу башкарыла (мәндүб), так санда булса — әйбәтрәк була (өч яки биш, яисә җиде), бу вакытта тәһарәт (вүду) алдырылмый. Соңгы тапкыр мәетне чайкаганда суга камфара яисә шуңа охшашлы нәрсә салына.

Аннары мәетне утырталар һәм йомшак кына итеп эчен сыпыралар, әгәр нәҗес чыкса — бары тик нәҗесне юып алу гына да җитә.

Бу эш тәмамлангач, мәетне корытып сөртәләр, башы һәм сакалына хуш исле әйбер сөртелә (ләкин зәгъфран белән түгел),



www.darul-kutub.com

сөжүд урыннары (маңгай, борын, ике кулы, ике тезе, ике аягы) — аларга хөрмәт йөзеннән — камфара белән каплана.

Мәетнең чәчләре таратылмый, тырнаклары (сынганнарыннан кала) киселми, башындагы чәче һәм сакалы алынмый (моның кирәге юк), бу эшләрне башкару мәкруһ-тәхрими гамәл булып тора.

**Мәетне кәфенләү**

Ирләр кәфене өч өлештән — изар, камис һәм лифафадан тора, шулай ук кайбер төбәкләрдә чалманы кулланалар. Изар һәм лифафа — кеше буеның башы ягыннан да, аягы ягыннан да утызар сантиметр озынрак материя кисәкләре. Камис — муеныннан алып үкчәсенә кадәр ике озынлыктагы материя. Камисның уртасы Т хәрефе сыман кисеп куела. Өч кат кәфенләү мөмкинлеге булмаса, изар һәм лифафа белән генә чикләнү дә җитә. Сәбәпсез көе ике кат кына чорналса — мәкруһ — гөнаһлы гамәл булыр.

Кәфен аша мәетнең тәне күренмәсен, ул кәфенсез кебек булмасын. Кәфен чиста булуы шарт.

Кәфен өлешләрен түбәндәге тәртиптә җәеп куялар. Башта лифафа җәелә, аның өстенә изар, ә аннары — камис куела. Юылган мәетне башын камисның Т рәвешле кисеменә туры китереп салалар, башын кигезәләр һәм камисның калган өлеше белән үкчәсенә кадәр каплыйлар. Шуннан соң изар һәм лифафага урыйлар. Ураганда һәрвакыт уң яктан башлыйлар. Кәфенлек сүтелмәсен өчен, аны баш очыннан, аяк табаныннан һәм уртадан бәйләп куялар.

Хатын-кыз кәфенлеге биш өлештән: дирга (бөркәнчек), изар, лифафа, хымар (ахирәт күлмәге) һәм хиркадан тора. Дирга ирләрнең камис дип аталган өлеше кебек. Хымар дигәне — өч терсәк буе материя. Хирка — күкрәгеннән ботына кадәрле материя кисәге. Хатын-кыз кәфенен ирләрнеке сыман җәяләр. Юылган мәетне диргага салалар, башын Т сыман кисемгә кидерәләр, дирганың калган өлеше белән гәүдәне муеннан алып үкчәсенә кадәр каплыйлар. Шуннан соң чәчләрен ике толым итеп үрәләр, күкрәгенә салалар, хырка белән каплыйлар. Шуннан соң чәчләрен хымар белән каплыйлар, аннары изар

һәм лифафа белән чорныйлар. Шулай ук, чишелмәсен өчен, өч урыннан бәйләп куярга мөмкин.

Кәфенләү алдыннан аны (ирләрнекен дә, хатын-кызныкын да) хуш исле әйбер белән эшкәртәләр.

Мәетнең чәчен алмыйлар, тырнагын кисмиләр.

Кәфенләгәннән соң, мәетне өйдән алып чыгу алдыннан, дога кылу өчен имамга һәм аның туганнарына аның янәшәсендә утырышырга кирәк. Аннары имам кыскача вәгазь сөйли, вафат булучыга дога кылу кагыйдәләре турында нәсыйхәт бирә. Гореф-гадәт буенча, барысы да күмәкләшеп эчтән генә йөз тапкыр тәһлил *(Лә иләһә илләл-лаһу)* әйтә, аннары имам кыска сүрә яки аятьләр укый һәм үлгән кеше хакына кычкырып дога кыла.

**Җеназа намазы**

Җеназа намазы мөселман җәмәгатенең бурычы (фарыз кифая) булып тора. Җеназа намазын мөфти, яки казый, яки мөхтәсиб, яки имам укый. Бу кешеләрнең укырга мөмкинлеге булмаганда — имам рөхсәт иткән кеше укый. Җеназа намазын укыганда мәрхүмнең: *«Фәлән кеше укыса иде»,* — дигән васыяте исәпкә алынмый. *(Имам булганда башка кешенең **(хәтта васыять буенча булса да!)**, мөхтәсиб булганда — имамның, казый булганда — мөхтәсибнең, мөфти булганда — казыйның, әмир булганда — мөфтинең җеназа намазы укуы дөрес булмый.)*

Намаз түбәндәге тәртиптә башкарыла: мәетне җәмәгать алдына башын уңга каратып, Кәгъбәтуллаһка перпендикуляр рәвештә яткыралар. Имам мәетнең күкрәге турысына баса, калган мөселманнар аның артында рәтләргә тезелә, әлеге рәтләрнең бердән артыграк — өч, биш яисә җиде рәт булуы шарт. Җеназа намазын кайтарып уку мөмкин булмаганлыктан, аңа тәяммүм белән басу да рөхсәт ителә. *(Мәетнең Аллаһы каршында дәрәҗәсе озатучылар саны белән түгел, җеназа намазында катнашучылар саны белән бәяләнә.)* Җеназа намазы укуны башлау турында кычкырып әйтелә. Имам, кулларын күтәреп, беренче тәкбирне әйтә һәм аннары «Сәнә» догасын укый.

www.darul-kutub.com

سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ وَتَبَارَكَ اسْمُكَ وَتَعَالَى
جَدُّكَ وَلَا إِلَهَ غَيْرُكَ

**«Субөхәәнәкәл-лааһүммә үә бихәмдикә үә тәбарәкәс-мүкә үә тәгәәләә җәддүкә үә ләә иләәһә гайрүк».**

*Мәгънәсе: «Әй Аллаһы, Сиңа дан һәм мактау булсын. Синең исемең мөбарәк һәм дәрәҗәң олуг. Синнән башка бернинди илаһи зат юк».*

Аннан соң икенче тәкбирне әйтә һәм Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават чыга.

اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٌ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدُ , كَمَا
صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمِ إِنَّكَ حَمِيدٌ
مُجِيدٌ, اَللَّهُمَّ بَارِكَ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ ,
كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ إِنَّكَ
حَمِيدٌ مُجِيدٌ

**«Әллааһүммә салли галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибраһиимә үә галәә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид. Әллааһүммә бәәрик галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибраһиимә үә галәә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә рәхмәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә дә рәхмәтеңне бир. Дөреслектә, Син — мактаулы һәм олуг зат. Йә Рабби, Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә бәрәкәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә дә бәрәкәтеңне бир. Дөреслектә, Син — мактаулы һәм олуг зат».*



www.darul-kutub.com

Шуннан соң имам өченче тәкбирне әйтә һәм мәеткә дога кыла.

Әгәр дә мәет ир кеше булса, түбәндәге дога укыла (түбәндәге догалар татарча да укыла ала):

اَللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَ مَيِّتِنَا وَ شَاهِدِنَا وَ غَاءِبِنَا وَ
ذَكَرِنَا وَ أُنْثَانَا وَ صَغِيرِنَا وَ كَبِيرِنَا *
اَللّٰهُمَّ مَنْ أَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَأَحْيِهِ عَلَي الْإِسْلاَمِ * وَ
مَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهِ عَلَي الْإِيمَانِ *
اَللّٰهُمَّ إِنْ كَانَ مُحْسِنًا فَزِدْ فِي إِحْسَانِهِ * وَ إِنْ كَانَ
مُسِيءًا فَتَجَاوَزْ عَنْهُ

**«Әллааһүммә-гъфир лихәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа'ибинә үә сагииринәә үә кәбииринәә үә зәкәринәә үә үнсәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә әхйиһии галәл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү галәл-иимән. Әллааһүммә ин кәәнә һәәзәл-мәй'йиту мүхсинән фәзид фии ихсәәниһии үә ин кәәнә мүси'ән фәтәжәәүәз гәнһ».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, тереләребезне дә һәм үлгәннәребезне дә, монда булучыларны да һәм монда булмаучыларны да, кечкенәләребезне дә һәм олыларыбызны да, ирләребезне дә һәм хатыннарыбызны да ярлыка. Йә Рабби, тере булганнарыбызга ислам дине буенча яшәргә насыйп ит, ахирәткә китүчеләргә иман белән вафат булырга насыйп ит. Йә Рабби, әгәр ошбу мәет изге кеше булса — изгелеген арттыр, әгәр гөнаһлы кеше булса — гөнаһларын гафу кыл».*

www.darul-kutub.com

Хатын-кыз булганда, түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَ مَيِّتِنَا وَ شَاهِدِنَا وَ غَاءِبِنَا وَ
ذَكَرِنَا وَ اُنْثَانَا وَ صَغِيرِنَا وَ كَبِيرِنَا *
اَللَّهُمَّ مَنْ اَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَاَحْيِهِ عَلَي الْاِسْلاَمِ * وَ
مَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَي الْإِيمَانِ *
اَللَّهُمَّ إِنْ كَانَتْ مُحْسِنَةً فَزِدْ فِي إِحْسَانِهَا * وَ إِنْ
كَانَتْ مُسِيءَةً فَتَجَاوَزْ عَنْهَا

**«Әллааһүммә-гъфир лихәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа’ибинә үә сагииринәә үә кәбииринәә үә зәкәринәә үә үнсәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә әхйиһии галәл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү галәл-иимән. Әллааһүммә ин кәәнәт мүхсинәтән фәзид фии ихсәәниһәә үә ин кәәнәт мүси’тән фәтәҗәәүәз гәнһәә».**

Баланы яисә акылга сай кешене җирләгәндә түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَ مَيِّتِنَا وَ شَاهِدِنَا وَ غَاءِبِنَا وَ
ذَكَرِنَا وَ اُنْثَانَا وَ صَغِيرِنَا وَ كَبِيرِنَا *
اَللَّهُمَّ مَنْ اَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَاَحْيِهِ عَلَي الْاِسْلاَمِ * وَ
مَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَي الْإِيمَانِ *
اَللَّهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا فَرَطًا *
اَللَّهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا أَجْرًا وَ ذُخْرًا *

اَللَّهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا شَافِعًا مُشَفَّعًا *

**«Әллааһүммә-гъфир лихәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа’ибинә үә сагииринәә үә кәбииринәә үә зәкәринәә үә үнсәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә әхйиһии галәл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү галәл-иимән.**

**Әллааһүммә-җгәл һәәзәл-мәййитә ләнәә фәртан.**

**Әллааһүммә-җгәлһү ләнәә әҗран үә зүхран.**

**Әллааһүммә-җгәлһү ләнәә шәфигән үә мүшәффәгә».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, бу мәеткә безне җәннәттә каршы алучы булырга насыйп ит. Йә Аллаһы, бу мәетне безнең өчен шәфәгатьче кыл һәм шәфәгатеннән Үзең разый бул».*

Дүртенче тәкбирне әйтеп, имам сәламләүне тәмамлый.

Икенче, өченче һәм дүртенче тәкбирләрне әйткәндә куллар күтәрелми.

Җеназа намазын мәчет эчендә уку хупланмый.

**Мәетне җирләү**

Мәетне өйдән аягы белән алга каратып алып чыгалар, аннары гел башы белән алга табан алып баралар. Мәетне күтәреп баручылар алмашырга теләсә, алдан — уң яктан — башлыйлар. Сәгать теленә каршы юнәлештә алмашалар. Мәетне бары тик ирләр генә күтәреп бара. Мәетне тиз алып баралар, ләкин йөгермиләр, үлем турында уйлап барырга кирәк, дөнья мәшәкатьләре турында сөйләшергә, көлергә ярамый, шулай ук мәет алдыннан бару да тыела, бары тик аның артыннан гына барырга мөмкин; мәетне күмгәнче җиргә утырырга ярамый.

Кабернең тирәнлеге кеше буеның яртысыннан да ким булырга тиеш түгел; бераз тирәнрәк булса да ярый. Озынлыгы — мәет озынлыгы кадәр булырга, киңлеге — буеның яртысы кадәр булырга тиеш. Кабер кыйблага аркылы юнәлештә казыла. Кабернең иң астында кыйбла ягыннан ләхет алалар. Әгәр дә туфрак бик йомшак булса — ләхетне аста алсаң да ярый. Ләхетне кабер уртасыннан алырга ярамый.



www.darul-kutub.com

Мәетне ләхеткә куйганда түбәндәге доганы әйтәләр:

بِسْمِ اللّٰهِ وَ عَلَي مِلَّةِ رَسُولِ اللّٰهِ

**«Бисмилләһ үә гәләә милләти рәсулилләһ».**

*Мәгънәсе: «Мәетне Аллаһы исеме белән һәм Мөхәммәд пәйгамбәр милләтендә кабергә иңдерәбез».*

Ләхет эчендә мәетне уң ягына салалар, кәфеннең бәйләгән урыннарын чишәләр, ә ләхетне нинди дә булса материал белән ябалар. Болардан соң каберне күмәләр, бу вакытта имам Коръәннән («Та һа» сүрәсе, 55 нче аять) түбәндәге аятьне укый:

مِنْهَا خَلَقْنَاكُمْ وَ فِيهَا نُعِيدُكُمْ وَ مِنْهَا نُخْرِجُكُمْ تَارَةً أُخْرَى

«**Минһә халакнәкум үә фиһә нөгийдөкүм үә минһә нухриджөкүм тәәратән ухраа**».

*Мәгънәсе: «Без сезне җирдән ялрттык һәм үтереп янә җиргә кайтарабыз вә кыямәт булганда икенче мәртәбә сезне җирдән чыгарабыз».*

Кабер өстенә цемент яисә гипс измәсе салу һәм фото кую тыела.

Мәетне җирләгәннән соң имам яисә ул вәкаләт биргән зат «әл-Мүлек (Патшалык)» сүрәсен укый һәм җирләнүчене ярлыкауны сорый. Аннары, дүрт мөселман кабернең дүрт читенә утырып, мәетнең башы янында «Әлиф, ләм, мим» («әл-Бәкара (Сыер)» сүрәсенең башы), ә аягы янында «Лилләһи» догасын укый. Әлеге догаларны белмәүчеләр берәр тапкыр «Фатихә» һәм унберәр тапкыр «Ихлас» сүрәләрен укый. Аннан соң имам укылган сүрәләрне мәрхүмгә багышлый. Шуннары, кабер янында имам гына кала, так санда тәхлил әйтә һәм мондый сүзләрне кабатлый *(исемнәре мисал буларак кына китерелә): «Әй, Габдрахман Әхмәт улы (яки «Зөләйха Фатыйх кызы»), синең яныңа ике фәрештә килеп сорарлар:*

*«Синең Ходаң кем?» — «Минем Ходам Аллаһы тәгалә», — диярсең. Алар: «Синең пәйгамбәрең кем?» — дип сорар, син: «Минем пәйгамбәрем — Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм», — диярсең. Алар тагын: «Синең динең нинди?» — дип сорар, «Минем динем — Ислам», — дип җавап бирерсең».*

Мөселман кешесен — мөселман зираты саналмаган зиратта, ә мөселман зиратында исә ислам динендә булмаган кешене җирләү тыела.

Җирләү вакытында зиратка хатын-кызлар кертелми.

Кабер ташының уртача биеклеге — җирлекнең уртача кар катлавының иң өске ноктасыннан — илле *сантиметр*дан да артык булырга тиеш түгел (Татарстан өчен кабер ташының биеклеге сиксән биш *сантиметр*дан туксан *сантиметр*га кадәр булырга мөмкин).

**Өчесе, җидесе, кырыгы көннәре һәм елы мәҗлесләре**

Өчесе, җидесе, кырыгы көннәре һәм елы мәҗлесләрен үткәрү халык кабул иткән традиция булып тора. Әлеге мәҗлесләр түбәндәге тәртиптә үткәрелә.

Имам иң элек мәҗлескә килгән барлык кешеләрне дә сәламли, аннары утырып дога кыла:

اَللّٰهُمَّ أَنْزِلْنَا مُنْزَلًا مُبَارَكًا وَ أَنْتَ خَيْرُ الْمُنْزِلِينَ

**«Әллаһүммә әнзилнәә мөнзәлән мөбарәкән үа әнтә хайрул мөнзилиин».**

*Мәгънәсе: «Йә Аллаһы, безне бәрәкәтле җиргә төшерсәң иде, Син урнаштыручыларның иң хәерлесе» («Мөэминнәр» сүрәсе, 29 нчы аять).*

Аннан соң имам вәгазь сөйли, анда сүз, гадәттә, дөньяда кешенең вакытлыча гына булуы, гомернең бик тиз узуы хакында бара. Шулай ук, мәҗлестә катнашучыларга исламның төп төшенчәләрен җиткерергә мөмкин.

Вәгазь тәмамлангач, имам, мәҗлес кунаклары белән бергәләп, эченнән генә йөз тапкыр тәһлил әйтә. Аннары Коръ-



www.darul-kutub.com

ән-Кәримнән сүрәләр укый. Гадәттә «Йәсин» яисә «әл-Мүлек (Патшалык)» сүрәсе укыла, ә кайчакта имам алар урынына берничә кыска сүрә, мәсәлән — «Фатихә», өч тапкыр «Ихлас», «Фәләкъ (Таң)» һәм «Нәс (Кешеләр)» сүрәләрен укый. Алардан соң дога кылына, анда мәҗлес хуҗасының вафат булган туганнарының исемнәре санап чыгыла һәм мәҗлес багышланган кешенең исеме *(яисә мәҗлес үткәрүчеләр искә алырга теләгән кешеләрнең исемнәре)* атала.

Аннары мәҗлестә катнашучылар садака бирә һәм имам дога кыла:

اَللّٰهُمَّ احْفَظْ صَاحِبَ هَذِهِ الصَّدَقَةِ عَنْ جَمِيعِ الْبَلَايَا وَ الْآفَاتِ وَ اغْفِرْ ذُنُوبَهُ وَ أَكِّدْ إِيمَانَهُ وَ أَكْثِرْ أَمْوَالَهُ وَ وَفِّقْهُ عَلَي خَيْرِ مَقَاصِدِهِ

**«Әллааһүммә-хфәз сахибә һәзиһис-садәкати ганил-афәәти үәл-бәлииййәәти үәгъфир зүнүүбәһүү үә әккид иимәәнәһүү үә әксир әмүәәләһүү үә үәффикһү галәә хайри мәкасыйдиһ».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, ошбу садака бирүчене афәтләрдән һәм бәлаләрдән сакла һәм шулай ук аның гөнаһларын гафу ит. Аның иманын куәтлә, малын арттыр һәм аңа хәерле максатларына ирешергә насыйп ит».*

Һәр табында садака өләшенә.

Садака таратуның тәртибе түбәндәгечә. Иң әүвәл йорт хуҗасы — бер кеше — өләшә һәм аңа дога кылына. Башкалар акча өләшергә теләсә, ул уртага (тастымалга, тәлинкәгә һ. б.) салына һәм, имам дога кылганнан соң, мәчеткә яисә берәр мохтаҗ кешегә тапшырыла.

Ашаганнан соң имам, мәҗлестә катнашучылар белән бергәләп, тиешле доганы укый. Чисталыкны саклау максатыннан, мәҗлес башланганчы ризык куелган өстәлне каплап куярга да мөмкин, ләкин моны эшләү мәҗбүри түгел.

www.darul-kutub.com

**Зиярәт кылу**

Зиратка кергәндә, мәрхүмнәрне искә алып, түбәндәге доганы укыйлар:

السَّلَامُ عَلَيْكُمْ أَهْلَ الدِّيَارِ مِنْ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُسْلِمِينَ وَإِنَّا إِنْ شَاءَ اللَّهُ بِكُمْ لَاحِقُونَ أَنْتُمْ لَنَا فَرَطٌ وَنَحْنُ لَكُمْ تَبَعٌ نَسْأَلُ اللَّهَ الْعَافِيَةَ لَنَا وَلَكُمْ

**«Әссәләмү галәйкүм әһледдияр минәл мөэмининә үәл мөслиминә үә иннә иншәә Аллаһү бикүм ләхикүүн әнтүм ләнәә фәратун үә нәхнү ләкүм тәбагүн нәсәлүЛлаһал гафия ләнәә вә ләкүм».**

*Мәгънәсе: «Әй, бу йортларның әһелләре! Сезгә Аллаһы тәгаләнең сәламе булсын. Аллаһы тәгалә дөньядан үткәннәргә вә сездән калганнарга да рәхмәт кылсын. Сез — бездән әүвәлге кешеләрсез, без — сездән соң калган кешеләрбез. ИншАллаһ, әлбәттә, сезгә кушылырбыз...».*

Зиратта Коръән сүрәләре укырга һәм үлгәннәргә дога кылырга кирәк. Гадәттә, анда «әл-Мүлек (Патшалык)» сүрәсе укыла.

Кабер янында булганда исерткеч эчемлекләр куллану, шәмнәр, веноклар, ясалма чәчәкләр кую рөхсәт ителми.

Шулай ук, кабер өстенә ятарга яисә аның өстенә утырырга һәм аңа басарга ярамый.

Үзеңнең берәр туганыңны эзләү максаты белән каберләр арасында йөрергә мөмкин, ләкин бары тик кабер ташларын уку өчен генә каберләр арасында йөрү хупланмый.

Зиратта кече һәм олы йомышны үтәү рөхсәт ителми.

**Рамазан ае**

Татарстан Республикасында рамазан аеның башлану һәм тәмамлану вакытын, Корбан гаете җитүне Үзәкләштерелгән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчелеге билгели. Шул сәбәпле, имам тиешле күрсәтмәләргә таянырга бурычлы.

www.darul-kutub.com

**Ифтар мәҗлесләре**

Ахшам намазына утыз-кырык минут кала җыелалар. Вәгазь сөйләнә, Коръән укыла, садакалар бирелә.

Авыз ачар вакыт җиткәч, имам үзе яисә аның ярдәмчесе — мәзин — азан әйтә. Шуннары, имам мәҗлестәгеләр белән бергә авыз ача һәм түбәндәге доганы укый:

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْنَا وَ بِكَ آمَنَّا وَ عَلَيْكَ تَوَكَّلْنَا وَ عَلَي رِزْقِكَ أَفْطَرْنَا فَاغْفِرْ لَنَا يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْنَا وَ مَا أَخَّرْنَا

**«Әллааһүммә ләкә сумнәә үә бикә әәмәннәә үә галәйкә тәүәккәлнәә үә галәә ризкикә әфтарнәә фәгъфирлии йәә гаффаарү мә каддәмнәә үә мәә әххәрнәә».**

*Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризалыгың белән авыз ачам. Әй гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».*

Шуннан соң ахшам намазын укыйлар. Имам ифтар оештыручыларны намаз уку өчен урын әзерләү зарурлыгы хакында кисәтеп куйса — яхшы. Ашаганнан соң, имам яки аның ярдәмчесе дога кыла:

الحَمْدُ للهِ الَّذِي أَطْعَمَنَا وَ سَقَانَا وَ جَعَلَنَا مِنَ الْمُسْلِمِينَ. اَللَّهُمَّ أَطْعِمْ مَنْ أَطْعَمَنَا وَ اسْقِ مَنْ سَقَانَا وَ ارْزُقْنَا مِنْ نِعَمِ الْجَنَّةِ.

**«Әлхәмдү лилләһилләзии атгамәнәә үа сәкаанәә үа җәгаләнә минәл мөслимиин. Әллаһуммә атгыйм мән атгамәнә үаскый мән сәкаанә үарзукнәә мин нигамил җәннәти».**

*Мәгънәсе: «Безне ашаткан, эчерткән һәм мөселман иткән Аллаһыга барлык мактау һәм хәмед-сәна булсын».*

Шулай ук әлеге доганы татарча яки ифтарда катнашучыларның туган телләрендә дә уку мәслихәт.

Ураза тотучыларга кыен булмасын өчен, ашый башлаганчыга кадәр өстәлдәге ризыкларны каплап куйсаң — яхшы.

**Тәравих намазы**

Тәравих намазы рамазан ае буена һәр төндә ястү намазының сөннәтеннән соң егермешәр рәкәгать укыла.

Һәр дүрт рәкәгатьтән соң аз гына ял итеп алырга кирәк. Ял иткәндә бер тапкыр тавыш белән *(кычкырып)* түбәндәге зикер әйтелә:

سُبْحانَ ذِي الْمُلْكِ وَالْمَلَكُوتِ سُبْحانَ ذِي الْعِزَّةِ
وَالْعَظْمَةِ وَالْقُدْرَةِ وَالْكِبْرِياءِ وَالْجَبَرُوْتِ سُبْحانَ
الْمَلِكِ الْحَيِّ الَّذِيْ لَا يَنامُ وَلَا يَمُوتُ سُبُّوْحٌ
قُدُّوْسٌ رَبُّنا وَرَبُّ الْمَلَائِكَةِ وَالرُّوْحِ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ
نَستَغْفِرُ اللهَ نَسْأَلُكَ الجَنَّةَ وَ نَعُذُ بِكَ مِنَ النَارِ

**«Субхәәнә зил-мүлки үәл-мәләкүүт. Субхәәнә зил-гыйззәти үәл-газамәти үәл-кудрәти үәл-кибрийә’и үәл-җәбәруут. Субхәнәл-мәлики-хәййил-ләзи лә йөмүт. Суббухүн куддүүсүр-раббил-мәләә’икәти үәр-руух. Ләә иләәһә ил-ләллаһү нәстәгъфирул-лааһ. Нәс’әлүкәл-җәннәтә үә нәгуүзү бикә минән-наар».**

*Мәгънәсе: «Җирдәге һәм күктәге мәхлукатның хуҗасы булган Аллаһы тәгаләне данлыймын. Көч, кодрәт һәм бик олуглык иясе булган Аллаһы тәгаләне данлыймын. Бөтен галәмнең патшасы һәм беркайчан үлмәячәк, һәрвакыт терек булучы Аллаһы тәгаләне данлыймын».*

Соңгы ун көндә түбәндәге зикер тавыш белән *(кычкырып)* әйтелә:

سُبْحٰانَ الْمَلِكِ الْحَنّٰانِ الْمَنّٰانِ * سُبْحٰانَ الْمَلِكِ الدَّيّٰانِ *اَلْمَعْرُوفِ بِالْغُفْرٰانِ * اَلْمَوْصُوفِ بِالْاِحْسٰانِ * اَلْوَدٰاعُ، اَلْوَدٰاعُ، يَا شَهْرَ رَمَضٰانَ * اَلْفِرٰاقُ، اَلْفِرٰاقُ، يٰا شَهْرَ التَّرٰاوِيحِ وَ خَتْمِ الْقُرْآنِ*لا إِلٰهَ إِلاَّ اللّٰهُ نَسْتَغْفِرُ اللّٰهَ. نَسْأَلُكَ الْجَنَّةَ وَ نَعُوذُ بِكَ مِنَ النّٰارِ.

Тәравих намазыннан соң җәмәгать белән бергә кычкырып витер намазы укыла, ә «Конут» догасы исә эчтән генә укыла. Башка вакытта витерны ялгыз гына *(эчтән)* укыйлар.

**Садака**

Имам яисә мәзин, шәхсән үзенә яки мәчет тартмасына садака алганда, түбәндәге доганы укый:

اَللّٰهُمَّ احْفَظْ صَاحِبَ هَذِهِ الصَّدَقَةِ عَنْ جَمِيعِ الْبَلَايَا وَ الْآفَاتِ وَ اغْفِرْ ذُنُوبَهُ وَ أَكِّدْ إِيمَانَهُ وَ أَكْثِرْ أَمْوَالَهُ وَ وَفِّقْهُ عَلَي خَيْرِ مَقَاصِدِهِ.

**Әллааhүммә-хфәз сахибә hәзиhис-садәкати ганил-а-афәәти үәл-бәлиййәәти үәгъфир зүнүүбәhүү үә әккид иимәәнәhүү үә эксир әмүәәләhүү үә үәффикhү галәә хайри мәкасыйдиh».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, ошбу садака бирүчене афәтләрдән һәм бәлаләрдән сакла һәм шулай ук аның гөнаһларын гафу ит.*

*Аның иманын куәтлә, малын арттыр һәм аңа хәерле максатларына ирешергә насыйп ит».*

Доганы шулай ук татарча яки садака бирүченең туган телләрендә дә уку мәслихәт.

Әгәр дә мәчеткә килүчеләр үзләренең вафат булган туганнары, якыннары яки дуслары өчен садака бирсә — Коръәннән кыска сүрә яки аятьләр укып — аны садака бирүченең теләге буенча багышларга кирәк.

**Исем кушу**

Имам яңа туган баланың исемен аның әти-әнисе белән алдан ук килештерсә — яхшы. Исем ислам дине традицияләренә туры килергә тиеш. Әгәр дә баланың әти-әнисе ислам принципларына каршы килә торган исем сайласа, имам аны төзәтергә яки башка исем сайларга ярдәм итәргә бурычлы. Ата-ана һаман да элек сайлаган исемне тәкърарласа, имам исем кушудан баш тартырга да хокуклы. Исем кушу алдыннан имам вәгазь укый, мәҗлестә катнашучыларга — яңа туган баланың әти-әнисенә — Хак Тәгаләнең никадәр шәфкатьле булуын аңлата, баланы дөрес тәрбияләүнең әһәмияте, аның ата-анага карата хокуклары турында сөйли.

Исем кушу түбәндәге рәвештә үтә.

Баланы, аякларын кыйблага юнәлтеп, өстәлгә яисә караватка салалар. Аннары имам, аның баш очына басып, кыйблага карап азан әйтә, азан догасын укый һәм баланың уң колагына аның һәм атасының исемен әйтә. Мәсәлән, *«Габдрахман улы Мәхмүд»* яисә *«Фатыйх кызы Гайшә».* Алга таба ул камәт төшерә. Камәттән соң баланың сул колагына иелә һәм аның исемен әйтә. Аннан соң имам түбәндәгечә дога кыла:

اَللَّهُمَّ أَنْبِتْهُ فِي الْإِسْلَامِ نَبَاتًا حَسَنًا وَ اجْعَلْهُ
مَسْعُودًا فِي الدُّنْيَا وَ الْآخِرَةِ

**«Әллаһуммә әнбитһү фил исләми нәбәтән хәсәнән вүҗгалһү мәсгудән фиддунья үәл әәхирә».**

*Мәгнәсе: «Йә Раббым, ошбу баланы ислам динендә тәрбияләп үстер һәм аны ике дөньяда да бәхетле ит».*

Шулай ук дога татар телендә яисә баланың әти-әнисе туган телләрендә дә укылса — бик күркәм. Мәсәлән: *«Йә Раббым Аллаһы! Бу бала ислам динен куәтләүче, ата-анасына игелекле, миһербанлы-шәфкатьле, тәүфыйклы бала булса иде. Ата-аналарына тигезлек, саулык-сәламәтлек белән аны үстерергә насыйп итсәң иде».*

**Яңа йортка күченгәч үткәрелә торган Коръән ашы**

Яңа өй җиткергәч, квартир яисә йорт сатып алгач уздырыла торган мәҗлес азан әйтүдән башлана, шуңа да мәҗлесне намаз вакытына туры китереп оештырырга кирәк. Аннары имам вәгазь укый. Вәгазьдә имам Аллаһы тәгаләнең кешегә нинди зур игелекләр кылуы өчен рәхмәтле булу зарурлыгын искә төшерә. Аннан соң Коръән укыла *(«әр Рәхман (Рәхимле)» сүрәсе)*, имам Аллаһыдан яңа торак хуҗаларына мал-мөлкәт, иркен тормыш, сәламәтлек һәм бәхет сорый. Чәй эчкәннән соң, гадәттәгечә, дога кылына.

**Имамның өс-баш киеме**

Көндәлек гыйбадәтләр вакытында имам түбәтәй *(яисә чалма)* һәм чапан кияргә тиеш.

Бәйрәм намазлары вакытында имамга чалма чалу һәм бәйрәм чапаны кию зарур.

Имам шулай ук мәхәллә кешеләренә намазга — түбәтәйдән, мәчеткә килгәндә аякларына оекбашлары киелгән булуны исләренә төшерергә тиеш.

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

Централизованная религиозная организация –
Духовное управление мусульман Республики Татарстан

ПОЛОЖЕНИЯ
о проведении богослужений и религиозных обрядов
имам-хатыйбами ЦРО – ДУМ РТ

Казань. Хузур. 1436/2014

На татарском языке

Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте

Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ

Оригинал-макеттан басарга кул куелды: 19.12.2014.
Форматы 84×108 1/32.
Тиражы 2000 д.

“Хузур” нәшрият йорты. 420111 Казан, Лобачевский урамы, 6.
Тел./факс: +7 (843) 202-07-74.
http://huzur.ru; электрон почта: huzur.inform@mail.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Лобачевский урамы, 6.
Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте;
Казан, Газовая урамы, 19.
Россия ислам институты.

«Зур Казан» типографиясе.
420095 Казан, Серов урамы, 4а.
Бирелгән электрон әйләнешкә туры китерелеп бастырылды.

www.darul-kutub.com